Министрлык, сабый беренче сыйныфка барганда ике телне дә тигез дәрәҗәдә белергә тиеш, дигән таләп куя. Шуңа күрә балалар бакчаларында эшләүче рус телле тәрбиячеләрнең дә татар телен өйрәнүләре таләп ителә. Чөнки балалар  эшчәнлек вакытында өйрәнгән сүзләрен, сөйләм үрнәкләрен көн дәвамында, уеннар барышында  кулланырга тиешләр. Димәк, моңа кадәр балалар  бакчаларында татар телен белмәгән тәрбиячеләргә дә хәзер татарча өйрәнергә туры киләчәк. Моны истә тотып, республика күләмендә рус телле тәрбиячеләрне татар теленә өйрәтү буенча төрле эшләр башланып китте. Бу юнәлештә  Казан арты Милли кадрлар әзерләү үзәге актив эшчәнлек алып бара.

2 тапкыр үткәрелгән “Мәктәпкәчә белем һәм тәрбия учреждениеләренең рус телле тәрбиячеләрен татар теленә өйрәтү” курсларында Республикабызның төрле районнарыннан килгән рус телле 25 тәрбияче  татар телендә сөйләшергә өйрәнде.

Курслар Фәтхуллова К.С. һәм  Зарипова З. М. лар тарафыннан төзелгән 144 сәгатьлек программага нигезләнеп үткәрелде.  Һәр дәрес берничә аралашу ситуациясен үз эченә алып, шуларга бәйле тел һәм сөйләм берәмлекләрен гамәли үзләштерү, коммуникатив күнекмәләрне үстерү максатын күздә тотып алып барылды.

Курслар үткәннән соң да без тәрбиячеләр белән даими аралашып торабыз. Алар үзләренең эш тәҗрибәләре белән уртаклашалар, без үз тарафыбыздан кирәк булган методик ярдәм күрсәтәбез.



